Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

# «Мин - мөселман, чөнки мин - татар»?

Түбән Кама 2009

بسم الله الرحمن الرحيم

## Кем ул татар?

إن الحمد لله نحمده و نستعينه و نستغفره و نعوذ بالله من شرور أنفسنا و سيئات أعمالنا من يهده الله فلا مضل له و من يضلل فلا هادي له و أشهد أن لا إله إلا الله وحده لا شريك له و أشهد أن محمدا عبده و رسوله، أما بعد...

Хакыйкатьтә, иң хәерле сүз – Аллаһ тәгаләнең сүзе, вә иң хәерле юл – пәйгамбәребез Мөхәммәднең (ﷺ) юлы. Шушы ике асыл белән өммәтебезнең әүвәлгеләре туры вә хак юлда булдылар. Ул ике асыл, бу дөньяда да, ахирәттә дә кешенең уңышка вә бәхеткә ирешү юлы. Кем дә кем аларга тотынса – туры юлда булды, ә кем алардан ераклашса, читләшсә – ул адашты вә хәсрәткә батты.

Бу китабымны, динебездән читләшкән татар милләтчеләренә һәм үзләренең күкрәкләренә сугып: «Мин татар», – дип шапырынган барча татарларга юллыйм!

Тарих фәне, бөтен галәмнең һәм хосусан барча кешеләрнең кичкән хәлләрен күрсәткән, бөек бер фәндер. Тарихны белү, кешегә бик зур файдалар бирә, чөнки тарихтагы адәмләрнең хәлләрен белеп, кайсылары файда белән, ә кайсылары зыян белән тормышларын кичергәнен күрәсең. Бу шулай ук, дәүләт башлыкларына да зур гыйбрәт, чөнки тарихтан кем яхшылык белән идарә итеп файда алган, ә кем начарлык вә золым белән идарә кылып дәүләтләрне юкка чыгарганлыгы билгеләнә.

Бик зур кызганычка каршы, безнең әүвәлге төрек бабаларыбыз безгә үзләренең хәл-әхвәлләре һәм кичерелгән тормышлары хакында ачык кына тарих язмалары калдырмадылар. Шунлыктан да, без инде аларның дүрт яклап дошманнары булган руслар, кытайлар, римлылар һәм фарсыларның язмаларыннан кулланырга мәҗбүр булабыз. Шулай ук, беребезгә дә яшерен түгел, дошманнар тарихны язганда үзләре генә яхшы булып, бернинди дә кимчелексез булып калалар. Ул

дошманнар, төрекләрне ничек теләсәләр, шулай хурладылар. Хәтта безнең төрек нәселеннән булганнар да аларның шул язмаларын укып, үзләренең төрек икәннәрен онытып һәм дә этнография (нәсел-нәсәб) гыйлеменнән надан булу сәбәпле төрекләрне, монголларны, булгарларны һәм башка төрки халыкларны вәхшилек, кыргыйлык, явызлык вә башка начарлыклар белән сыйфатлап яздылар. Бәлки алар аны икенче берәүгә, яки урыска ярарга тырышып язганнардыр? Кайберәүләре үзләренең төрки халык булганнарыннан оялып, үз телләрендә сөйләшергә куркып исемнәрен дә урысныкына яки көнбатыш динсезләрнекенә алыштырдылар. Болар барчасы да динсезлектән, Аллаһның сине кем итеп тудырганлыгы белән килешмәү вә халыкның үз тарихын белмәгәнлектән икәнлеге көн кебек ачык. Мәсәлән, бер сабыйның әти-әнисен күршеләре яратмаганлыктан гел дә сүгеп вә начар сүзләр белән генә искә ала икән, бу сабый ул сүзләрнең мәгънәсен белмичә, аларны ятлый һәм шул сүзләрне әти-әнисенә карата куллана. Бу сабыйның акылы бар дип әйтеп булырмы? Монда да шулай ук, Аллаһу мүстәган.

Сер түгел, Ислам тарихларында бәян ителгәнчә, хәзерге вакытта җир йөзендәге барча Адәм балалары да Нухның عليه السلام өч баласыннан – Яфис, Сәәм һәм Хәәмнән – таралдылар. Әс-Сәүәйдий «Сәбәил әз-зәһәб фи мәгърифәти кабәил әл-гарәб» исемле китабында, шулай ук Ибен Халдүн, Ибен Сәгъдләр тарих китапларында искә алганча, төрекләр Нухның улы Яфискә, ә гарәпләр Сәәмгә, ә суданлылар, һиндлар һәм барча кара халыклар Хәәмгә тоташа.

Мөхәммәд Морат[1] үзенең «Мохтасар тарих гомуми» китабында: «Әсия кыйтгасында электән үк өч төрле кавем яши иде. Беренчесе төрек таифәседер, Әсиянең төньяк өлешендә күчмә халык хәлендә иделәр. Әсиянең көнчыгыш тарафында чинлылар (кытайлар), ә көньяк тарафында Һиндулар (индиялылар) иде», – дип әйтеп узды.

---

1 Рамзи булса кирәк, татар халкының мәшһүр гыйлем иясе вә тарихчысы, 19нчы гасырлар.

Ибен Халдүн вә ибен Сәгъдләр әйтүенчә, төрек нәселенә кыпчаклар, уйгурлар, булгарлар (хәзерге вакытта татарлар дип билгеле булган халык), монголлар, татарлар (хәзерге монгол җирлегендә булган бер кавем), башкортлар, черкеслар һәм башкалар керә. Аллаһу әгъләм.

Булгар сүзе билгеле бер илгә яки шәһәргә әйтелеп, һәм аның кешеләренә «Булгарлылар» диелә торган иде. Кайбер тарих китапларында бу кавемгә шулай ук «Бургар» «Бүләр» яки «Биләр» дип тә әйтелде. Ләкин иң билгеле булганы һәм дөресе, әйткәнебезчә ул инде «Булгар», Аллаһу әгъләм бихакыйкати әхвәл.

Булгар иле Кафказ тауларының төньягында булып, көньяктан Саратау, Пенза, Тамбуф һәм Тула белән чиктәш иде. Төньяктан Төньяк Туң диңгезгә кадәр сузылса, көнчыгыштан Урал тауларына һәм көнбатыштан Итил (Волга) елгасына кадәр (кайберәүләр әйтүенчә Балкан тауларына кадәр) җәелгән иде. Бу чикләр вакыты белән бик нык зураеп, вакыты белән (ягъни, хәзерге кебек) бик тә кечкенә булып та кала торган иде.

Гомумән, Булгар шәһәренең урыны, хәзерге вакытта Биләр (Бүләр) дип билгеле булган урын. Булгар шәһәреннән көньяктарак өлештә Сарай шәһәре була. Булгар кайчан һәм кем тарафыннан төзелгән икәнлеге хакында ачык кына мәгълүмәтләр юк. Кемдер аны Булгар бин Күмери бин Яфис бин Нух төзегән һәм шуның исеме белән аталган дисә, икенче берәүләре Гыйсә عليه السلام туганчы ике гасыр кала төзелгән ди, ә өченчеләре Зүл-Карнәйн төзегән дигән фикерне дә әйтеп узалар. Болар инде барысы да сүзләр генә, һәм аны төзүчене төпченүдән файда бар микән?

Әбү Хәмид әл-Әндәлүсий үзенең язмаларында искә алуынча, бер изге вә салих кеше Булгар җиренә кергәч, бу җирнең патшасы һәм патшабикәсе икесе дә бик каты авыру булалар. Бу кеше аларга, минем динемә керсәгез, мин сезне дәвалыйм дигәч, алар икесе дә ризалаша. Аллаһ тәгаләнең әмере белән алар авыруларыннан арыналар һәм үзләре вә барча кавемнәре

Исламны кабул итәләр. Хазәрларның патшасы бу хәбәрне белеп бик тә ачулана һәм аларга зур гаскәр җыеп яу белән чыга. Теге изге вә салих кеше патшага: «Курыкмагыз һәм «Аллаһу әкбәр», – дип сугышыгыз, җиңәрсез», – ди, һәм хакыйкатьтә дә, җиңеп чыгалар. Моннан соң Хазәр патшасы алар белән солых төзи вә: «Мин сезнең гаскәрегездә зур гәүдәле ир-атларның бик яхшы атларга атланып сугышканнарын вә минем иярченнәремне үтергәннәрен күрдем», – ди. Изге вә салих кеше аңа: «Алар Аллаһ тәгаләнең гаскәре (фәрештәләре) иде», – дип җаваплый. Бу изге вә салих кешенең исеме Бүләр була, һәм вакытлар узып аны үзгәртеп Булгар дип әйтә башлыйлар.

Башка риваятьләргә караганда, Хазәрлар Булгарларны бик кимсеткәннән, алар Исламны кабул итеп хәлифәт сагына керәләр. Фикһ мәзһәбе итеп Әбү Хәнифә мәзһәбен сайлыйлар. Аллаһу әгъләм.

Булгарларның рәсми Исламны кабул итүләре һиҗри тәкъүим буенча 310нчы еллардан соң, әл-Мукътәдир Билләһ хәлиф вакытында була. Бу инде миләди тәкъүим буенча, якынча 940-945нче елларга туры килә.

Булгар әһелләренең асыл теле чуаш теленә якын була. Исламны кабул иткәннән соң, үз телләрен ташлап төрек теленә күчәләр. Бу инде гаҗәеп түгел, чөнки хәзерге вакытта ничек татарлар үз телләрен ташлап урыс теленә вә динсезлеккә күчүләре, безгә дәлил булып тора. Шулай ук, үзләрен «без татар милләтчеләре» дип шапырынган бәндәләр дә, үзләре дә, балалары да ана телләрен дә вә диннәрен дә белмиләр. Әллә бу аларга сәяси дәрәҗәләргә (депутатлык), акча-мал җыяр өчен бер кәсеп кенәме? Мин сезгә әйтер идем: «Булгар бабаларыгыз кәферләрнең явызлыгыннан Исламны кабул итеп кенә котылган кебек, сезгә дә хәзерге урыс вә башка кәферләрнең явызлыгыннан котылуга бер генә юл, ул – Исламга кайту!».

Ничек кенә булмасын, Булгарларның урта һәм ахыргы гасыр телләре – төрек теле. Моңа дәлил булып борынгы китаплар вә кабер ташларындагы язмалар тора.

Булгарларның Ислам кабул иткәч булган тормышлары, иң гүзәл вә иң күркәм агачны хәтерләтә. Ул агачны яхшы тәрбия белән генә үстереп булган кебек, Исламга килгәч иманны да яхшы вә файдалы гыйлем һәм гамәл белән генә үстереп була. Файдалы гыйлемнең асылы – Коръән һәм пәйгамбәребезнең сөннәте. Шуңа да, Булгарлар бик тә җитди рәвештә Коръән, сөннәт, фикһ һәм башка дини гыйлемнәрне өйрәнүгә керешәләр.

Булгарлар Исламны кабул иткән елларда, аларның иң беренче әмире Җәгъфәр бин Габдулла иде. Аннан соң солтанлык аның улы Әхмәдкә күчә. Әхмәд солтаннан соң идарәлек, улы Талибка кала. Талибтан соң тәхеткә Мөэмин утыра, аның вакытында урыслар белән кыпчаклар берләшеп Булгар иленә һөҗүм ясыйлар. Шушы вакыттан башлап, урыс кәферләре белән Булгар мөселманнары арасында дин белән бәйле сугыш башлана. Кайбер тарих китапларында, урыслар Булгарларның бай яшәүләреннән көнләшеп һәрвакыт аларны талар өчен һөҗүм ясый торган иделәр дип искә алынса да, әмма ләкин төп сәбәп булып, Карамзинның китапларында, урысларның диненә туры килмәгән Булгарларның дине иде дип әйтелә. Моңа дәлил итеп, Булгар (хәзерге вакытта татар) мөселманнарын чукындыруны китерергә була. Чөнки байлык талау гына булса, чукынган татарларларны да таларлар иде, ә инде аларга киресенчә, яхшы җирләр вә байлыклар гына бирелә торган булды. Урыслар вә кыпчаклар тарафыннан булган бу сугышларның нинди котычкыч вә вәхши икәнлеген әйтеп бетергесез.

Монда инде Коръәннән Аллаһ тәгаләнең ошбу сүзләрен китерү бик тә урынлы: **«Яһүдләр һәм насараларның диннәренә кергәнеңә чаклы, алар синнән һич тә риза булмаслар. Син аларга әйт: «Диндә Аллаһ һидәяте генә һидәят». Сиңа Коръәннән вә сөннәттән гыйлем**

**бирелгәннән соң аларның нәфесләре теләгән нәрсәләргә иярсәң, Аллаһ сиңа ярдәмче булмас».** (Бәкара: 120)

Шулай ук: **«Әгәр булдыра алсалар, сезне динегездән чыгарганчыга хәтле, алар сезнең белән сугышудан туктамаячаклар».** (Бәкара: 217)

Ошбу хәл, ягъни Булгарларның, урыслар вә кыпчакларга каршы дини көрәше 300 ел, Чынгызханның гаскәрендә булган, Монголия далаларыннан чыккан татарлар кавеме һөҗүм итә башлаганчыга кадәр дәвам итте.

Ибен әл-Әсир тарихында әйтеп узганча, һиҗри тәкъүим буенча 620 елларда, Чынгызлы татарлары урыс вә кыпчакларны көньяк-көнчыгыш якларда тар-мар иткәннән соң, Дербенд ягыннан Булгар илләренә һөҗүм иттеләр. Ләкин алар Булгарлылар тарафыннан җиңелеп, калганнары Бухарага, Чынгыз хан янына кире кайтып киттеләр.

Карамзинның язуынча, якынча 630нчы елларда, Булгарлар белән урыслар арасында алты еллык вәхши сугыштан соң, Георгий Всеволод белән солых төзелеп, әсирләр белән алышынгач, Булгарлар килешүләренә хыянәт кылып, Абрам исемле урыс сәүдәгәрен Мөхәммәд пәйгамбәргә иярмәгән өчен үтерәләр, дип яза. Әр-Рамзий әйтүенчә, Булгарлар аны Мөхәммәд пәйгамбәргә иярмәгән өчен түгел, ә бәлки сөекле пәйгамбәребезне мыскыллап көлгәне, яки бер-бер хыянәте өчен үтерәләр. Чөнки, ул вакытта Булгарлар пәйгамбәребезне мыскылларга һичкемгә дә юл куймый торган иделәр, һәм хәзер дә куймаячаклар, дип әйтеп узды.

Әй Аллаһ! Әр-Рамзийнең сүзләре хәзерге татарларга да туры килеп, хак булса иде! Кызганычка каршы, динебездән читләшеп, кәферләргә ярарга тырышуыбыз, безне ошбу аянычлы хәлләргә китерде.

Карамзин әйтүенчә, Чынгыз хан вафат булганнан соң, Уктай аның урынына утырды. Кытай патшаларын үзенә буйсындырганнан соң, Бату ханга өч йөз мең гаскәр биреп, Каспий диңгезенең төньяк җирләрен яуларга җибәрде. Урал елгаларын узып, Булгар җирләрен яулап һәм Булгар патшасын вә

туган-тумачаларын үтергәннән соң, урысларга хәбәр барып җиткәнче үк, аларны тар-мар итте.

Ләкин Мәрҗәний әйтүенчә, Булгар солтаны Илһәм хан татарларның бик күп гаскәр белән килүен белгәч тә, солых төзер өчен Урал елгасына таба чыгып, аларны каршы алды.

Шушы вакыттан алып Булгарлар, татарлар мәмләкәте астына керә һәм вакытлар узып «татарлар» дип атала башлыйлар, ләкин алар үзләренең диннәрен вә ил эчендәге идарә эшләрен үзләре хәл итүне саклап калды. Моннан соң Булгарларның тыныч кына, рәхәт тормыш итүләре, диннәреннән читләшүгә һәм үзара бүлеш-талашка китерде. Ә урыслар һәрвакытта да уяу булып, сугышка әзерләнеп торулары, Бөек Ислам дәүләте булган Булгар иленең киләчәктә юкка чыгуына зур сәбәп булды.

Чыңгызның хатыннарыннан вә кәнизәкләреннән кырыкка якын баласы була. Ләкин аның мирасына һәм мал-мөлкәтенә татар һәм монгол кабиләләреннән генә лаеклылары – дүртәү иде. Дүрт улының иң олысы Җүҗий, аннары Чагатай, аннары Түлий һәм Уктай иделәр. Дүрт улына да мәмләкәтен бүлеп, Җүҗийгә Кыпчак, Дагыстан, Булгар, Рус һәм барча Аурупа илләрен бирде. Төркестан һәм Урта Әсия җирләрен икенче улы Чагатайга бирде. Фарсы, Гыйрак һәм шул якка таба булган Гарәп вә башка җирләрне өченче улы Түлийгә бирде. Түлий ул инде Мәнгү һәм Багдадка һөҗүм иткән Һүләкүнең әтисе. Чыңгыз үзе яшәгән һәм Кытай җирләрен кече улы Уктайга бирде.

Безгә мөһим булганы, белгәнебезчә Чыңгыз Булгар җирләрен олы улы Җүҗийгә бирде. Җүҗий үлгәннән соң идарәлек Җүҗийнең олы улы Бату ханга күчте, аннан соң Бату ханның улы Сыртык ханга күчте. Сыртык ханны кайбер тарихчылар Батуның энесе дисәләр дә, әмма ләкин без дөресрәк дип белгәне, ул Батуның улы иде, Аллаһу әгъләм.

Сыртык хан тәхеттә озак утырмады, күп булса ике елдыр, ул үлгәннән соң идарәлек Бәрәкә ханга күчте. Бәрәкә хан Чыңгызлылар арасыннан иң беренче Исламны кабул итүче һәм Ислам тарихында иң гүзәл кеше булып калды.

Әйткәнебезчә, Чынгызның өченче улы Түлийгә Фарсы һәм Гарәп илләре бирелде. Түлийдән соң аның улы Һүләкү тарихта котычкыч гамәл кылды. Ул мөселманнарның хәлифлеге булган Багдадка һөҗүм ясап, шәһәрне яндырды, мөселманнарны үтерде хәтта тарих китапларында әйтелгәнчә, ул бер атна эчендә биш миллион мөселманны үтереп, аннары ике атна буена Ефрат елгасы кып-кызыл кан белән акты, Аллаһу мүстәган!

Бу хәлләрне Бәрәкә хан белеп Һүләкүдән мөселманнарның үчен алырга карар кылды. Һүләкү Мисырга җиткәнче, барча Чынгызлыларның әмире һәм аның бертуган абыйсы булган Мәнгүнең үлү хәбәрен ишетеп, үзенең гаскәренең дүрттән өч өлеше белән кире кайту юлына чыкты. Бу форсатны Бәрәкә хан бик тә уңышлы кулланды, һәм якынча һиҗри тәкъүим буенча 663нче елларда (1280-1290м) Һүләкүнең гаскәрен тар-мар итте.

Шулай итеп, безне булгар яки татар дип атасыннар, ләкин безнең булгар бабаларыбыз Исламны кабул иткәннән соң, барча тарихыбыз да Аллаһ тәгаләнең дине белән бәйле.

## Кем ул мөселман?

Мөселман төшенчәсе Ислам төшенчәсеннән алынган.

Исламның тел ягыннан булган төшенчәсе: Бирелү, баш ию, буйсыну дигәнне аңлата. Ә гомуми, дини һәм истилахи төшенчәсе: Аллаһ тәгалә риза булып, барча кешеләргә дә ахыргы вә йомгаклаучы дин итеп Ислам динен ихтияр кылды. Бу дин белән Ул иң ахыргы пәйгамбәр булган Мөхәммәд бин Габдуллаһны кешеләргә вә җеннәргә, Аллаһны рубубиятта да[2], иләһияттә дә[3] һәм күркәм исемнәрендә вә камил сыйфатларында да[4] бер дип белсеннәр, һәм Аның шәригатен торгызсыннар өчен һидәят итеп җибәрде.

Шулай итеп, ***мөселман – ул, Аллаһны рубубиятта да, иләһияттә дә һәм күркәм исемнәрендә вә камил сыйфатларында да бер дип танып, Аңа буйсынучы вә Аның хөкемнәре буенча яшәүче кеше була.***

Асылда, барча пәйгамбәрләр дә Ислам дине белән җибәрелде, чөнки Аллаһ тәгалә җеннәрне һәм кешеләрне Үзенә гыйбадәт кылыр өчен генә халикъ кылды:

•وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنْسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ• الذاريات: ٥٦

Мәгънәсе: **«Җен белән кешене иллә мәгәр Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә халикъ кылдым».**

---

2 Тәүхид рубубия. Ул — Аллаһ тәгалә барча нәрсәне халикъ кылучы, ризыкландыручы, тергезүче вә үлекләндерүче — дип, Аңа ныклы ышану. Чөнки «Раббы нәрсәне теләсә, шуны эшли», — дип иман китерү була. Пәйгамбәребез ﷺ вакытында, хәтта Мәккә мөшрикләре дә бу тәүхидне таныйлар иде, мәгънәсе: **«Әгәр син алардан: «Сезне кем халикъ кылды?», — дип сорасаң, алар, әлбәттә: «Аллаһ халикъ кылды», — диячәкләр».**

3 Тәүхид үлүһия. Ул: «Хакыйкатьтә, бер Аллаһ сөбхәнәһү вә тәгалә генә гыйбадәткә лаек» — дип ышану һәм кабул итү. Ошбу тәүхидне мөшрикләр кабул итмәделәр һәм шушы тәүхидтә пәйгамбәрләр белән алар арасында каршылык чыкты.

4 Тәүхид әл-әсмәә вә әс-сыйфаат. Ул — Аллаһ тәгаләне Үзен Коръәндә һәм пәйгамбәребез ﷺ Аны сөннәтендә сыйфатлаган күркәм исемнәр вә камил сыйфатлар белән сыйфатлау.

Шушыны кешеләргә бәян кылыр өчен, Ул пәйгамбәрләр җибәрде:

•وَلَقَدْ بَعَثْنَا فِي كُلِّ أُمَّةٍ رَسُولًا أَنِ اعْبُدُوا اللهَ وَاجْتَنِبُوا الطَّاغُوتَ
فَمِنْهُمْ مَنْ هَدَى اللهُ وَمِنْهُمْ مَنْ حَقَّتْ عَلَيْهِ الضَّلَالَةُ فَسِيرُوا فِي
الأَرْضِ فَانْظُرُوا كَيْفَ كَانَ عَاقِبَةُ الْمُكَذِّبِينَ• النحل: ٣٦

Мәгънәсе: **«Өмmәтләрнең һәрберсенә расүлләр күндердек, фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз вә Аллаһтан башкага гыйбадәт итүдән сакланыгыз дип. Ул өммәтләрнең итагать иткәннәрен Аллаһ һидәяткә салды вә итагать итмәгәннәренә адашуны беркетте. Инде җир өстендә йөрегез вә күрегез — ялганчыларның ахыры ничек булды?».**

Кешеләр туры вә хак юлдан адашып расүлләргә тиешле булган карашны чиктән тыш узып, пәйгамбәрләргә җибәрелгән иләһи китапларны үзгәрткәч һәм Аллаһка ширек ката башлагач, Аллаһ тәгалә әүвәлге диннәрне гамәлдән чыгарып, Үзе риза булган ошбу хак Ислам дине белән Мөхәммәдне ﷺ җибәрде.

**Пәйгамбәребез ﷺ хакында кыскача белешмә:**

Мөхәммәд ﷺ миләди тәкъвим буенча 571нче елда дөньяга килде. Билгеле булганча, ул әнисенең карынында чакта ук әтисез, ә инде алты яше тулмас борын әнисе дә вафат булып, тулысынча ятим калды. Дүрт яшенә кадәр ул чүллектә күркәм сөйләү телен өйрәнеп, бәнү Сәгъд кабиләсендә тәрбияләнде һәм ул вакытта аның сөт анасы Хәлимә бинт әл-Хәрис булды. Шулай ук анда тәрбияләнгән вакытта Аллаһның әмере белән фәрештәләр аның күкрәген ачып, кара төеннән тазарттылар, юдылар. Кечкенә чагында барча пәйгамбәрләр кебек үк көтү көтте, һәм җәһилият әһелләренә хас булган гыйбадәтләрдән, күңел ачулардан ерак булды. Пәйгамбәрлек килгәнче үк кешеләргә үзенең гаделлеге вә күркәм сыйфатлары белән билгеле булды. Кырык яшендә пәйгамбәрлек иңде, һәм бу дөньядан киткәнчегә кадәр ул вазифаны җиренә җиткереп

үтәде вә алтмыш өч яшендә вафат булды. Мөхәммәд ﷺ кешелек дөньясы күргән, бердән-бер искиткеч кеше булды.

**Тугры хәлифләр:**

Тугры хәлифләр дүртәү. Алар пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ иң хәерле сахәбәләре, шулай ук Ислам дәүләтен төзүчеләрнең әүвәлгеләре.

**1. *Әбү Бәкер әс-Сыддийкъ р. ганһү (11-13 һ/632-634)***

Ул пәйгамбәребез ﷺ вафат булганнан соң беренче хәлиф булды. Аның вакытында эшләнгән мөһим эшләрдән: Мөртәдләргә каршы сугыш, Коръәнне бергә җыю, Гыйрак һәм Шәм җирләрен ачарга Үсәмә бин Зәйд җитәкчелегендә гаскәр җибәрелүе һ.б. Аның хәлифлеге ике елда өч айдан артык дәвам итми, һәм миләди тәкъүим буенча 634нче елда Әбү Бәкер ؓ вафат булды.

**2. *Гомәр бин әл-Хаттаб р. ганһү (13-23 һ./634-644 м.)***

Әбү Бәкердән ؓ соң хәлифлек Гомәргә күчте. Аның вакытында, Сәгъд бин Әбий Үәккас җитәкчелегендә булган «әл-Кадисия» сугышында фарсыларны җиңделәр, һәм Гамр бин әл-Гас җитәкчелегендә Фәләстыйн һәм Мисыр җирләре ачылды. Шулай ук, Гомәр ؓ һиҗри тәкъүимне кертте, дәүләтнең идарә ысулын тәртипкә салды, шәһәрләр төзетте һәм башка шәһәрләр вә төбәкләр белән элемтә чараларын төзеде.

Һиҗри тәкъүим буенча 23нче елның 27нче зүлхиҗҗә аенда (644 м.), Гомәр ؓ мәчеттә кешеләр белән иртәнге намазны укыганда, Әбү Лү‘лү‘ә әл-Мәҗүси тарафыннан ханҗәр белән кадап үтерелде.

**3. *Госман бин Гаффан р. ганһү (23-35 һ./644-656 м.)***

Әбү Бәкер һәм Гомәрдән соң мөселманнарның хәлифе булып Госман ؓ калды. Аның вакытында Исламга каршы баш күтәрүләр бастырылды, шулай ук башка илләрне ачу дәвам итте. Мисыр җирләренең вәлие, Габдуллаһ бин Әбий әл-Сәрәх, төньяк Африка илләрен яулады, ә көнчыгышта мөселман гаскәрләре Габдуллаһ бин Әбий Гамир җитәкчелегендә Аму-

дарья елгасын узып, Төркестан җирләренә керде (хәзерге Урта Әсия илләре; Үзбәкстан, Таҗикстан, Төрекманстан һ.б.). Аның вакытында Ислам диңгез флотына нигез салынды, һәм мөселманнар Кипр һәм Родос утрауларын ачтылар, шулай ук, 652нче елда «Зәт әл-Сауарий» сугышында, Византияларны җиңделәр. Госманның ﵁ кушуы буенча Зәйд бин Сәбит Коръәнне мусхафка туплап, мөселманнарны бер кыйраатка җыйды.

Госман бин Гаффан ﵁ һиҗри тәкъүим буенча 35нче елның зүлхиҗҗә аенда (656м.) Габдуллаһ бин Сәбә‘ исемле яһүдинең мөселманнар арасына коткы салуы нигезендә Мисыр, Басра һәм Күфәнең кайбер хавариҗлары тарафыннан үтерелде.

**4.** ***Гали бин Әбий Талиб р. ганһү (35-40 һ./656-661 м.)***

Госман ﵁ үтерелгәч, хәлифлек мәсьүлияте Галигә ﵁ йөкләнде. Ул беренче булып фетнәдә катнашкан вәлиләрне читләштерүдән, һәм «Бәйтүл малга» тиешле өлешләрне кайтарудан башлады. Шулай ук, алдагы хәлифләр кебек, Ислам өчен булган изге гамәлләрне дәвам итте. Гали ﵁ һиҗри тәкъүим буенча 40нче елның 17нче рамазан аенда (661м.) Габдуррахман бин Мүлҗим исемле хариҗий тарафыннан үтерелде.

**Ислам тарихында яңа җирләрне ачкан кайбер хәрби җитәкчеләр:**

**1.** Халид бин Валид. Сугыш мәйданында искиткеч сәләтле булганы өчен «әл-Мү‘тәһ» газвәтеннән соң пәйгамбәребез ﷺ аны «Сәйфуллаһ» (Аллаһның кылычы) дип атады. Шулай ук, ул, мөртәдләр күтәргән фетнәне бастырды, шуннан соң аны Әбү Бәкер ﵁ Гыйракка җибәрде. Гыйрактан соң ул Шәм җирләренә юнәлде һәм «Ярмүк» сугышында Византиялыларны тар-мар итте.

**2.** Әбү Губәйдәһ бин әл-Җәррах; Димәшкъ, Хумс, Антакия һәм Хәләбне буйсындырды.

**3.** Сәгъд бин Әбий Үәккас; Фарсы җирләрен ачты.

**4.** Гукъбәһ бин Нәфигъ әл-Фәһрий; Кайраван шәһәрен төзеде, һәм аның, башка җирләрне яулап ачуы Атлантик океанына кадәр җитте.

**5.** Муса бин Нусайр; Төньяк Африка илләрен ачуны тәмамлады, һәм Тарикъ бин Зиядне Андалус илен (хәзерге Испания, Португалия һәм Франциянең көньягын) ачарга җибәрде. Ул Андалусны алып Франция белән Испания арасындагы Пиренеи тауларына хәтле җитте.

**6.** Кутәйбәһ бин Муслим әл-Бәһилий; Ислам илләрен ачуда көнчыгышка табан юнәлеп Кытай чикләренә хәтле җитте.

**7.** Мөхәммәд бин Касим әс-Сәкафий; Ул Синд әһелләренең Ислам кабул итүенә сәбәпче булды.

**8.** Салахетдин әл-Әюбий; 573һ (1187м) елда «Хыттыйн» сугышында насараларны җиңеп Кудс мәчете җирләрен азат итте.

**9.** Заһир Бибарс; Аның җитәкчелегендә 658һ (1260м) елда «Гайн Җәлут» сугышында монголлар тар-мар ителде.

**10.** Мөхәммәд әл-Фәтих; 858һ (1453м) елда Константинопольне ачты.

**Исламдагы кайбер күренекле шәхесләр:**

Ислам – гыйлем һәм зур мәдәният дине. Бу өлкәләрдә иң күренекле шәхесләрдән:

**1.** ***Фикһ гыйлемендә:*** Имам Әбү Хәнифә (80-150һ), имам Мәлик (179һ), имам Шәфигый (204һ), имам Әхмәд бин Хәнбәл (241һ). Фикһ өлкәсендә сахәбәләрне искә алмыйча әйтеп узганда, бу галимнәр әһле сүннә вәл-җәмәгадә дүрт фикһ мәзһәбенә нигез салучылар.

**2.** ***Тәфсирдә:*** Сахәбәләр вакытында; Гали бин Әбий Талиб, Габдуллаһ бин Габбас, Габдуллаһ бин Гомәр, Габдуллаһ бин Мәсгуд, Үбәй бин Кәгъб һәм Зәйд бин Сәбит. Тәбигыйннәр вакытында; Сәгыйд бин Җүбәйр, Җәбир бин Язид, Мөҗәһид бин Җәбр, Гата бин әбий Рабәх, Гыйкримәһ, Тауус бин Кәйсән,

Суфиян бин Гуяйнәһ, Үкәйгъ бин Җәррах, Исхак бин Раһәүәйһ (Раһүйһ) һәм башкалар.

Тәфсирдә иң мәшһүр китап әһелләре; Ибен Җәрир әл-Табарий, ибен Кәсиир, әл-Бәгауий, ибен әл-Җәүзий, әш-Шәүкәний һ.б.

**3. *Хәдистә:*** Пәйгамбәребездән ﷺ иң күп риваять кылучылар, Әбү Һурайраһ رضي الله عنه белән Гайшә радый Аллаһу ганһә. Алардан соң Габдуллаһ бин Гомәр, Әнәс бин Мәлик һәм Габдуллаһ бин Габбаслар رضي الله عنهم .

Иң мәшһүр хәдисләр җыентыгы; имам Бохари, Мөслим, әбү Дауд, ибен Мәҗәһ, Тирмизий, Нәсәий, имам Мәлик, имам Әхмәд һ. б.

**4. *Гарәп телендә:*** Әбү әл-Әсүәд әд-Дү‘лий, әл-Хәлил бин Әхмәд һәм Сибәүәйһләр нәхү кагыйдәләрен билгеләүдә иң күренекле шәхесләр булдылар. Әдәбият вә шигрияттә Хәссән бин Сәбит пәйгамбәребез ﷺ вакытында иң мәшһүр шәгыйрләрдән икәнлеге билгеле иде. Үмәүия вакытында Җәрир, Фәраздәк һәм Әхталлар иде, ә Габбасилар вакытында әбү Тәммәм, Бәхтәрий, әбү Галәә әл-Мәгрибий һәм ибен Румийлар иде. Шулай ук Габдулхәмид бин Яхъя һәм Җәхизлар күренекле әдәбиятчылардан булдылар.

## Исламның иң мөһим фикерләре һәм тәгълиматләре:

Ислам дине ул саф тәүхид дине, һәм аның мөһим фикерләре вә тәгълиматләре бар. Ошбуларны аңлатып түбәндәгеләрне әйтербез:

### – Ислам нигезләре, иман һәм ихсан:

### 1. Ислам нигезләре:

Ислам биш нигезгә нигезләнгән: «Лә иләһә илләАллаһ Мүхәммәдүр-расүлүАллаһ», – дип таныклык кылу, Намазны

торгызу, Зәкәт бирү, Рамазанда ураза тоту һәм мөмкинчелеге булган кешегә Кәгьбәтуллаһка барып Хаҗ кылу.

**А) «Лә иләһә илләАллаһ Мүхәммәдүр-расүлүАллаһ»,** – дип таныклык кылу, ул – тәүхид гакыйдәсенең асылы, иманның нигезе һәм исламның беренче рөкене. Бу кәлимә иман белән көферлекне аеручы чик, кем дә кем аны чын күңелдән вә ихлас белән әйтеп гамәл кылса, ул мөэмин-мөселман булды. Үлер алдыннан кемнең ахыргы сүзе ошбу кәлимә булса, ул кеше Җәһәннәмнән сакланыр. Пәйгамбәребез ﷺ бу хакта болай диде:

«من شهد أن لا إله إلا الله و أن محمدا رسول الله، حرم الله عليه النار» (الجامع الصغير و زيادته، تحقيق الألباني: صحيح )

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем дә кем «Лә иләһә илләАллаһ Мүхәммәдүр-расүлүАллаһ», – дип таныклык бирә икән, Аллаһ тәгалә ул кешегә Җәһәннәмне хәрам кылды (яки ул Җәһәннәм утында мәңгелеккә калмас)».***

Бу кәлимәнең мәгънәсенә килгәндә, болайрак аңлатырга мөмкин: Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы бер иләһ тә вә бер зат та юк. Без Аллаһтан башка беркемгә дә, бернәрсәгә дә итагать итмибез, һәм Ул хәрам кылганны гына хәрам кылабыз вә Ул хәләл кылганны гына хәләл диябез, Аның шәригатен генә кабул итәбез, һәм Ислам канунына каршы килгән һичнәрсә белән дә риза булмыйбыз. Мүхәммәдүр-расүлүАллаһның мәгънәсенә килгәндә, болайрак аңлатырга мөмкин: Мөхәммәд Аллаһның илчесе, ул нәрсә хәбәр иткән булса, без аны ышанып кабул итәбез, ә нәрсә белән әмер иткән булса – шуңа итагать итәбез, ә нәрсәдән тыйган һәм кисәткән булса – аннан тыелабыз вә читләшәбез, һәм Аллаһка гыйбадәтне ул күрсәткәнчә генә кылабыз.

Шәһәдәт кәлимәсе, ул кешене Исламга кертә торган ачкыч, һәм бу сүзләр белән мөселманның өстенә шәригать хөкемнәре йөкләнә. Шулай ук, бу кәлимә Аллаһка иләһияттә, рубубияттә һәм күркәм исемнәрдә вә сыйфатларда булган гакыйдәнең камиллеген үзенә ала.

**Б) Намаз:** Аллаһ тәгалә мөселманнарга тәүлегенә биш тапкыр намаз укып бәдәни гыйбадәт кылырга фарыз итте. Шулай ук намаз кеше белән Раббысы арасындагы тыгыз бәйләнеш, чөнки адәм баласы намаз белән үзен Аллаһ тәгаләгә ныграк буйсындыра һәм үзен бозыклыклардан, фәхишәлектән, явызлыклардан, адашудан вә Җәһәннәм утында мәңге калудан саклый.

**В) Зәкәт:** Зәкәт ул арту һәм пакьләү дигәнне аңлата. Ә инде шәргый төшенчәсенә килгәндә болайрак була: Шәригать белән билгеләнгән малдан, билгеләнгән кешеләргә, билгеләнгән вакыттан соң бирелә торган бер өлеш мал.

**Г) Рамазанда ураза тоту:** Рамазан аенда ураза тоту Исламның дүртенче баганасы булып тора. Бу айда мөселман кешесе Аллаһның әмеренә итагать итеп вә Мөхәммәд пәйгамбәргә ияреп, таң беленгәннән алып кояш баеганчыга кадәр ураза нияте белән ашаудан, эчүдән һәм хатыннары белән җенси мөнәсәбәткә керүдән тыелып тора.

**Д) Хаҗ кылу:** Мөмкинчелегеннән килгән мөселманга гомерендә бер тапкыр Аллаһ йорты Кәгъбәтуллаһка барып хаҗ гамәлен үтәү фарыз булып тора. Хаҗ ул шәригать белән билгеләнгән урыннарны, билгеле вакытта, билгеле гамәлләр белән максат итеп зиярат кылу.

***Бу биш багананы үтәмәгән татарлар үзләренең: «Без мөселман», – дип күкрәк сугуларында уйлансыннар!***

## 2. Иман:

Аллаһка иман – ул, кеше белән Раббысы арасындагы иң зур вә көчле бәйләнеш. Иман – ул, тел белән әйтү, йөрәк белән раслау, ныгыту һәм тән белән гамәл итү. Иманның бик күп тармаклары бар, иң югарысы «Лә иләһә илләАллаһ», – дип әйтү, ә иң түбәне – юлдан киртәне яки йөрүчеләргә авырлык китерә торган әйберне алып ташлау. Оялчанлык – иманның бер тармагы. Иманның асыл нигезләре: Аллаһка, Аның фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәрләренә, ахирәт көненә һәм тәкъдирнең яхшысына вә яманына ышану.

## 3. Ихсан:

Ихсан – ул, син Аллаһны күрмәсәң дә, Аны күргән кебек гыйбадәт кылу, чөнки Ул сине күрә. Шуңа да ихсан диннең иң югары мәртәбәләреннән булып тора.

## – Коръән һәм сөннәт:

Коръән – ул, Җибрил عليه السلام аша пәйгамбәребезгә ﷺ иңдерелгән Аллаһ тәгаләнең кәләме (сүзе). Ул әүвәлге «әл-Фәтихә» сүрәсеннән алып ахыргы «ән-Нәс» сүрәсенә кадәр мусхафта (китап рәвешендә) җыйналган. Коръәнне үзгәрешләрдән вә бозылулардан Аллаһ тәгалә Үзе саклый, һәм ул ничек пәйгамбәребезгә ﷺ иңгән булса, Кыяматкә кадәр шулай саклана.

Коръән, ул ахыргы иләһи китап булып, аңа кадәр иңдерелгән барча китапларның да (мәсәлән, Тәүрат, Инҗил, Зәбүр) хөкемен юкка чыгарды.

Сөннәт — юл дигәнне аңлата, ләкин аның шәргый мәгънәсе: Ул — пәйгамбәребезгә ﷺ тоташкан нәрсәләр. Булсын ул аның әйткән сүзләре, кылган фигыльләре яки нинди дә булса гамәлне күреп, аңа карата дәшмичә калганлыгы.

Коръән һәм пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәте, Ислам дине гакыйдәсенең вә шәригатенең асыл чыганаклары булып тора. Беркемгә дә бу ике чыганактан читләшергә ярамый. Барча низаглар вә мәсьәләләр ошбу ике чыганакка таянып хәл ителергә тиеш, һәм кешеләр тарафыннан уйланып чыгарылган вә куелган кануннарга бернинди дә урын булырга тиеш түгел.

## – Исламның өстенлеге һәм күркәмлеге:

Ислам – ул, иләһи хак дин. Исламда кеше бернинди арадашсыз турыдан-туры Аллаһ белән бәйләнә. Нәсараларда яки башка барча диннәрдә дә, кеше кемдер (атакайлар яки башкалар) аша үзләренең иләһләренә гыйбадәт кыла торган булса, ә Исламда кеше турыдан-туры Аллаһка гына гыйбадәт кыла, Аннан гына сорый, Аңа гына тәүбә итә һ.б. Кешеләрнең

Ислам шәригатенә булган хаҗәтләре, һавага яки ашау-эчүгә булган хаҗәттән дә ныграк. Чөнки һавасыз яки ашау-эчүсез кешенең тәне генә үлә торган булса, ә инде Ислам шәригатсез кешенең тәне дә, җаны да, йөрәге дә үлә. Уйланган кешегә моның аермасы җир белән күк аермасы кебек. Ислам диненнән башка бу дөньяның төзәлүе вә кешеләрнең бәхеткә ирешүе мөмкин түгел.

Ничек инде атакай (поп) синең гөнаһларыңны кичерә алсын, чөнки ул бит шундый ук, синең кебек гөнаһ кыла торган гади бәндә?! Уй-фикер йөрткән кешегә бу көн кебек ачык!

Ислам дине кешеләрнең бу дөньяда да, ахирәттә дә файдаларын булдыру, бер-берсенә кардәшлек, тигезлек, киңәш, гаделлек, хаклык, ярдәмләшү, бәндәләрнең хокукларын һәм иминлеген саклау дине. Шулай ук, Ислам ихтирам, күркәм әхлак, килешүләрне вә әманәтне һәм мөселман булмаганнарның хокукларын, шәригать буенча тиешлечә үтәү дине.

Ислам, ул гыйлем өстәү вә наданлыкны бетерү дине. Чөнки Исламнан башка бер диндә дә, кешенең нинди дә булса эшләгән гамәленә дөрес дәлилләр китерү юк. Мәсәлән, кайбер урыс христианнары кул белән ишарәтләп чукынмыйлар, ни өчен дигәндә, алар үзләре үк моңа, «Гайсәнең عليه السلام чукынуы хакында бер җирдә дә язылмаган», — дип әйтәләр.

Исламнан башка, барча диннәр дә дәлилсез, буш сүзгә генә корылган. Әгәр дә ул христианнар поплардан: «Нигә болай, ә монда нигә тегеләй эшләргә кирәк», — дип сорасалар, аларга поплар: «Сорама, шулай эшләргә кирәк һәм бетте», — дип җаваплыйлар. Шуңа да, хәзерге вакытта Аллаһның рәхмәте илә, уй-фикер йөрткән кайбер урысларның Ислам динен кабул итүләре гаҗәеп хәл түгел.

Ә инде, Исламда, һәрбер эшләнгән гамәлгә Коръәннән аятьләр яки пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләре китерелә.

Кеше Аллаһ тәгаләнең колы һәм аның бу дөньяда төп вазифасы, Аллаһка коллык белдереп Аңа гыйбадәт кылу вә шәригатен үтәү. Исламдагы барча хөкемнәр дә Аллаһ тара-

фыннан билгеләнгән, шуның өчен дә, кешеләр тарафыннан уйланылган бер хөкемгә дә урын юк.

**«Берәү Ислам диненнән башка динне үзенә алса, аның дине вә гамәле һич кабул булмый, һәм ул ахирәттә хәсрәтләнүче вә һәлак булучыдыр».**

## — Дөньяның хакыйкый сурәте:

Дөнья, ул имтихан һәм гамәл йорты, ә инде ахирәт, дөньядагы гамәл өчен тиешлесен алу йорты. Кем бу дөньяда тузан бөртеге кадәр изгелек эшләсә — тиешле әҗер-савабын алыр, ә кем инде тузан бөртеге кадәр явызлык эшләсә — җәзасын алыр. Беркем дә иртәгә нәрсә эшләсен һәм кайда вә ничек үләсен белми, шуңа да, азга гына да кичектерми Аллаһ тәгаләнең ихлас колы булырга ашык, чөнки сине Җәннәттә нигъмәт, яки инде Җәһәннәмдә газап көтә, Аллаһ сакласын икенчесеннән.

**«Мал һәм балалар дөнья тереклегенең зиннәтләредер, әмма мәңге калачак нәрсә изге гамәлләрдер, ул изге гамәлләр Раббың хозурында, дөнья малыннан һәм балалардан хәерлерәктер, нигъмәт йөзеннән һәм кешенең өмет иткән нәрсәсенең яхшырагыдыр. Кыямәт көнендә тауларны җир белән күк арасында очырып йөртербез вә син ул көндә җирне, тау, таш, урман булмаганы хәлдә ялангач күрерсең, вә ул көндә барча кешеләрне кубарырбыз, кубармыйча һичкемне калдырмабыз. Кубарылгач саф-саф итеп Раббыңа тапшырылырлар. Тәхкыйк хозурыбызга килдегез әүвәлдә халык кылганыбыз кебек, ялангач хәлегездә, бәлки сез уйладыгыз каберләрегездән кубарырбыз дигән вәгъдәбездә тормабыз, дип. Ул көндә һәркемнең гамәл дәфтәре алдына куелыр вә гөнаһлы кешеләрне дәфтәрләренә язылган гөнаһларыннан куркучы күрерсең һәм әйтерләр: «Безгә һәлакәтлек килде, ни булды бу дәфтәргә, гөнаһларыбызның кечкенәсен дә, зурысын да калдырмаган, мәгәр барын да санаган, язган», — дип. Вә кылган эшләренең җәзасын хәзерләнеп куел-**

**ган табарлар. Раббың һичкемгә золым итмәс».** [Әл-Кәһф 46-49]

Дөнья белән мавыгып, аның ләззәтенә чумган гафил (гамьсез) бәндәләрнең мисалы, көймәгә утырып бер утрауга хаҗәтләрен үтәргә килеп туктаган кешеләр кебектер. Көймә туктагач та, көймәнең хуҗасы аларга хаҗәтләрен үтәү белән көймәгә ашыгырга вә соңламаска кушты, әгәр дә соңласалар, көймәнең китүе белән кисәтте. Ул кешеләр көймәдән төшеп, утрауның төрле якларына таралдылар. Кемнәрдер хаҗәтләрен үтәү белән тиз генә көймәгә ашыктылар, һәм көймә буш булу сәбәпле, анда иң яхшы вә күңеленә иң хуш килгән урыннарга утырдылар. Икенчеләре утрауның матурлыгы, андагы чәчәкләр, кошлар сайраганы белән беразга мавыктылар. Аннары, көймәнең китәсе исләренә төшеп анда таба ашыгып барсалар да, көймәдә бик иркен урнаша алмадылар, чөнки беренчеләре иң яхшы урыннарны алып бетергәннәр иде инде. Өченчеләре шулай ук утрауның матурлыгы белән мавыгып, хәтта андагы матур чәчәкләрне, ташларны һәм башка зиннәтле нәрсәләрне дә үзләре белән көймәгә алып керергә уйладылар. Алар көймәгә килгәндә бик кысык булу сәбәпле, алган әйберләрен куярга урын тапмагач үзләренең җилкәләрендә вә сыртларында күтәрергә мәҗбүр булдылар. Тора-бара ул нәрсәләрнең авырлыгыннан һәм чәчәкләрнең бозылып начар ис килә башлавыннан үзләре интегә башлады. Алган нәрсәләре өчен ничек кенә үкенсәләр дә, бер файдасы да булмады. Дүртенчеләре утрауның эченәрәк кереп андагы җиләк-җимешләрне татып, чәчәкләрне иснәп, агачларның матурлыгын карап көймәне бөтенләй оныттылар. Хәтта көймә хуҗасы аларны күпме генә чакырса да, аның тавышын ишетмәделәр. Алар шулай утрауның матурлыгы белән мавыкканда, аларны я ерткыч хайваннар куркыталар, я чәнечкеле үсемлекләр тәннәренә кадалалар, я ят тавышлар шомландыралар. Кайберәүләре көймә янына барып җитсәләр дә, анда урын тапмыйча яр буенда үлеп калдылар. Ә кайберәүләре утрауның зиннәтенә алданып калып, ерткыч хайваннар һәм дә зыянлы еланнар тарафыннан һәлак булдылар.

Бу, байлыкка вә матур тормышка алданып, үзләренең мәңгелек тормышка барасын оныткан дөнья әһелләренең мисалы. Акылы белән уй-фикер йөрткән кеше, вакытлыча булган дөньяның зиннәтенә алданып үзен мәңгелек бәхеттән мәхрүм итәрме?!

***Икенче мисал: [Ялангач кисәтүче]***

Дөнья әһелләре үзләренең балалары, маллары һәм байлыклары белән сәфәргә чыккан кешеләр кебек. Юлда барганда бик матур җиргә килеп чыгып, шунда йортлар вә сарайлар салып калырга ниятләделәр. Алар янына, үзләренең танышларыннан, тугрылыгы һәм әманәтлеге белән билгеле бер ир килеп чыгып: «Мин бу җиргә таба якынлашып килүче дошман гаскәрен күрдем, һәм алар сезне үтереп, малларыгызны үзләштерергә ниятлиләр. Миңа ияреп, минем артымнан барыгыз, мин сезне дошманнарыгыз белмәгән яхшы юл белән моннан алып чыгып коткарырмын», — диде. Аңа бик азы гына иярде, һәм ул калганнарга: «Әй кешеләр! Котылуга ашыгыгыз! Котылуга ашыгыгыз!», — дип кычкырды. Аны ишетүчеләр: «Без ничек инде бу җирләрне ташлап китик, без бит монда төпләндек һәм монда безнең малларыбыз, йортларыбыз вә байлыкларыбыз?!», — дип җавапладылар. Нәсыйхәтче аларга: «Һәркем үзенә иң кирәкле җиңел нәрсәләрен генә алсын һәм миңа ияреп котылсын, югыйсә үзе дә, малы да һәлак булачак», — дип кисәтте. Байлык хуҗаларына, аксөякләргә һәм дә идарә җитәкчеләренә бу нәсыйхәтләрне кабул итү бик тә авыр иде, һәм алар бу матур җирдәге күркәм тормышны калдырасылары килмәде. Шулаһ ук, уй-фикер йөртмәгән ахмаклар: «Мин дә бу кешеләр белән монда калам, чөнки аларның байлыклары да күп һәм мин дә бәлки алар кебек бай булып рәхәт тормышта яшәрмен, ә аларга берәрнәрсә булса — миңа да шул булыр», — дип уйлады.

Нәсыйхәтчегә иярүче аз гына кешеләр, дошман гаскәреннән котылып уңышка ирешә. Ә инде аңа иярмәүчеләр иртә белән дошманның һөҗүменә юлыгып үзләре дә, маллары да һәлак булдылар.

Бу мисалга, пәйгамбәребезнең ﷺ Бохарида һәм Мөслимдә килгән хәдисе турыдан-туры ишарәли.

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгалә мине пәйгамбәрлек белән җибәргәннең мисалы шундыйдыр: Бер ир-ат үзенең кавеменә килде дә: «Әй кешеләр! Мин үз күзләрем белән дошман гаскәренең килгәнен күрдем, һәм мин сезне бу куркыныч хәлдән ялангач кисәтүчемен[5]. Котылырга ашыгыгыз!», — диде. Бер төркем кешеләр аңа буйсынып, төннең әүвәлге өлешендә үк чыгып китеп тиз генә котылырга ашыктылар һәм котылдылар. Ә кешеләрнең икенче төркеме аңа буйсынмыйча, төннәрен үз йортларында үткәреп калдылар, һәм иртә белән дошман гаскәренең шәһәргә керүенә уянып үзләре дә, маллары да һәлак булдылар. Бу мисал, миңа буйсынып, мин чакырганга иярүчеләр, һәм миңа буйсынмыйча, мин чакырган хаклыкны ялганга чыгаручылар хакындадыр».***

Аллаһ сөбхәнәһү вә тәгалә байлыкны һәм фәкыйрьлекне ләззәтләнеп яшәр өчен түгел, ә бәлки ибтилә һәм имтихан максаты белән булдырды. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгалә әйтте: «Хакыйкатьтә, Без байлыкны, кеше намазын торгызсын өчен һәм дә зәкәтен бирсен өчен булдырдык. Әгәр дә адәм баласының бер үзәнлек малбайлыгы булса, ул икенчесе булуын теләр иде. Ә инде аның икенчесе дә булса, өченчесе булуын теләр иде. Адәм баласының карынын туфрактан башка һичнәрсә дә тутыра (туйдыра) алмас».[6]***

Аллаһ кешеләргә байлык белән Аның хакларын үтәргә кирәклеген бәян итте. Ә кем инде ул байлыкны тиешле урынга куя белмәсә, аңа карынын туфрак белән тутыру яхшырак.

Кемнәр Аллаһ тарафыннан бирелгән байлыкны Аңа гыйбадәт кылу өчен сәбәп итеп куллана белсәләр, алар бу

5 Гадәт буенча, гарәпләр күзәтеп торучы сакчыларны тау башларына куялар иде. Һәм әгәр дә, дошман якынлаша башласа, ул сакчылар башкаларга куркыныч килүне белдерер өчен өсләрендәге киемнәрен салып болгый торган иделәр.

6 «Мүснәд Әхмәд» Әбү Үәкыйд әл-Ләйсий риваяте, шәйх Әлбәний сахих диде (1639)

байлык белән кулланучы иң хәерле кешеләр булалар. Байлык хуҗасына файда китермәсә, аңа зыян китерүе көн кебек ачык. Шулай ук гыйлем, көч һәм патшалык та. Болар барсы да Аллаһка гыйбадәт кылып бәхеткә ирешү, яки шәйтанга буйсынып газапка ирешү өчен сәбәпләр булып торалар.

Кемнең генә булса да иртән торганда да, кич белән ятканда да максаты Аллаһның рәхмәтенә ирешү икән, Аллаһ тәгалә аның барча хаҗәтләрен дә Үзе үти. Ул кешенең йөрәген Үзенә мәхәббәт белән тутыра, телен Аны зикер итү белән мәшгуль кыла һәм тәнен Аңа итагатьтә вә гыйбадәттә булдыра.

Ә кемнең инде иртә торганда да, кич белән ятканда да барча максаты дөнья малына гына ирешү булса, Аллаһ тәгалә аны үз-үзенә калдыра. Ул кешенең йөрәге дөнья чүп-чарына, байлык вә байларга мәхәббәт белән тула, теле дә шул нәрсәләрне генә сөйли торган була, тәне дә шул нәрсәләргә хезмәт күрсәтә торган була, һәм ул башкаларга эш күрсәтүдә вә кемгәдер хезмәт итүдә ишәк кебек туктаусыз эшли торган хайванга әйләнә.

Кем генә булса да Аллаһ тәгаләгә мәхәббәт белдерүдән, Аңа коллык күрсәтүдән һәм Аңа итагать итүдән ераклаша торган булса, алар башка кешеләргә коллык, мәхәббәт һәм гомере буе аларга хезмәт итүләре белән бәлагә ирешәчәкләр. ***«Берәү Аллаһны искә алудан, Аның шәригате буенча яшәүдән  баш тартса, Без аңа шәйтанны беркетербез һәм ул шәйтан аңа якын булыр вә һич тә аннан аерылмас».*** [Әз-Зүхруф 36]

Ислам динендә булмаган кешеләрне адәми хайваннар дип атарга мөмкин. Чөнки алар белән хайваннар арасындагы аерма иллә-мәгәр тураеп басуда һәм сөйләшүдә генә чагыла. Ул адәми хайваннарның бөтен максаты, нинди генә юл белән булса да үзләренең шәһвәтләрен канәгатьләндерүдән генә гыйбарәт.

***Аларның кайберәүләре эт шикелле.*** Әгәр дә ул мең эт туярлык берәр үләксәгә очраса да, ул үләксәне башкаларга бирмичә сакларга тырышачак һәм аңа якынлашкан барча

этләргә дә ачуланып өрәчәк. Ул этнең барча максаты, үзенең корсагын нинди генә булса да ашамлык белән тутыру. Булсын ул үләксә яки бозылмаган ит, начармы-яхшымы, берсеннән дә ул җирәнми.

**«Әгәр теләгән булсак, ул кешене биргән аятьләребез белән бөек дәрәҗәгә күтәрер идек, ләкин ул дөньяга бирелде һәм нәфесенә иярде, аның мисалы эт кебек, этне орышсаң да, орышмасаң да телен салындырыр. Ошбу мисал: «Безнең аятьләребезне ялган диючеләрнең, ягъни Коръән белән вәгазьләнмәүче вә аның белән гамәл кылмаучы кешеләрнең мисалы. Коръәндәге хәбәрләрне сөйлә, шаять фикерләп аңларлар».** [Әл-Әгъраф 176]

Әгәр дә андый адәми этләрне ашатсаң, алар синең тирәли койрыкларын болгый-болгый ялагайланып йөриләр, ә инде аларга ашарга бирмәсәң, сиңа тешләрен күрсәтеп ырлый башлый.

***Ә икенчеләре ишәк шикелле.*** Алар авыр йөк ташу һәм ашау өчен генә халикъ кылынганнар. Ул адәми ишәкнең ашавын арттырган саен, аңа авыр эшен дә арттыралар. Ул иң телсез һәм иң «сукыр» аңгыра хайван. Шуңа да Аллаһ тәгалә Коръәндә, китапларны күтәреп һәм нәрсә күтәргәнлеген вә ул китапларда нинди гыйлем булганлыгын аңламаган вә гамәл дә итмәгән кешеләрне «алар ишәк кебек» дип сурәтләде.

***Өченчеләре вәхши вә ерткыч кебек.*** Аларның барча максаты кешеләргә дошманлык кылу һәм көчләре җиткән кадәр аларны түбәнсетү, изү. Мондый кешеләрнең табигате ерткыч хайваннарныкыннан бер дә аерылмый, һәм алар адәми сурәттә булган ерткыч хайваннар.

***Дүртенчеләре тычкан шикелле.*** Алар үзләре дә бозык һәм тирә-яктагы нәрсәләрне дә бозучылар.

***Бишенчеләре агулы еланнар вә чаяннар шикелле.*** Аларның нәфселәре бозык вә кабахәт, чөнки алар кешенең ачык һәм иң зәгыйфь урынына гына агуларын кадыйлар. Мондый төр адәми хайваннар үзләренең хөседлегеннән,

көнчеллегеннән башкаларны кабергә озатуда бер дә ятсынып тормыйлар.

***Алтынчылары дуңгыз шикелле.*** Мондый адәми хайваннар яхшы вә хәләлгә борылып та карамыйлар. Аларга пычрак вә бозыклык кирәк. Әгәр дә син аны хәләлгә вә яхшыга борып җибәрә яки нәсыйхәтли башласаң, ул ачулана вә сиңа үч кыла башлый.

***Җиденчеләре тавис (павлин) кошы кебек.*** Алар тавис кебек, үзләренең һичнәрсәләре булмаса да, башкалар алдында матурлану вә зиннәтләнүдән башка бернәрсә дә белмиләр. Урам теле белән әйткәндә «пантаватся итәргә яраталар». Һ.б.

Ошбу һәм башка юньсез сыйфатлары булган хайваннар белән кешеләр тәэсирләнмәсеннәр өчен, Аллаһ тәгаләнең бер хикмәте, аларның итләрен ашауны хәрам кылды. Аллаһу әгъләм.

## Мөхәммәд Мурат Рамзийнең «Тәлфикъ әл-әхбәр вә тәлкыйх әл-әсәр фи вакаигъ Казан вә Булгар вә мүлүк әт-Татар» китабыннан кайбер өзекләр:

### Бүл Или вакыйгасы

1903 елда, Казан тирәләрендә булган Бүл Или авылына урыс хөкемәте тарафыннан уку-укыту эшләрен тикшерү өчен билгеләнгән инспектор үзе белән ике-өч урыс укытучысы белән килеп чыга. Бу урыс укытучыларының берсе Бүл Или авылы мәктәбендә укытырга калып, калган икесе башка татар авылларына китергә тиеш була.

Алар бу авылның имамы һәм мәктәптә укытучы булган мулла Фазылҗан бин Мифтахетдин йортына килеп төшәләр. Исерек инспектор урыс укытучылары белән аның йортына

килгәндә, мулла Фазылҗан үзенең хәләл җефете белән мунчада була.

Мөселманнарда гадәт буенча, хатын-кызлар өчен аерым бүлмә була. Бу исерек инспектор мөселманнарның гадәтләрен белмәү һәм кәферләрдә ирләре дә, хатыннары да бергә буталышып яшәүләре сәбәпле, керергә рөхсәт тә сорамыйча, хатын-кызлар бүлмәсенә килеп керә. Бүлмәдә булган балалар, кеше сурәтеннән чыгып хайван сурәтенә кергән исерек урысны күреп бик тә нык куркып калалар. Алардан әти-әниләренең кайдалыгын сорагач, балалар: «Алар мунчада», — дип җаваплыйлар. Инспектор балаларның берсен әтиләренең тиз генә кайтуын таләп итеп, чакырырга җибәрә. Имам Фазылҗан тиз генә өенә кайтып керсә, хатын-кызлар бүлмәсендә исерек инспекторны күреп, бу бүлмәгә керергә ярамаганлыгын ничек кенә аңлатырга теләсә дә, исерек урыс моны аңларга теләми. Шуннан соң имам бу урысны көч белән йорттан куып чыгара да, ат арбасына утыртып җибәрә.

Бу хәлне белеп алган авыл кешеләре, исерек урыс инспекторының урамда атын туктатып тотып алалар да, берәүнең йортына алып кереп, бик шәп кенә кирәген бирәләр.

Волостной старшина моны белеп, тиз генә инспекторны авыл халкының кулыннан коткарып, атына утыртып җибәрә.

Исерек урыс инспекторы бу хәлдән исән котылгач, гаделлек хөкеменә (прокуратурага), «Урыс укытучылары алып килгән өчен мулла Фазылҗан мине кыйнады һәм авыл халкына үтерергә кушты», — дип ялган яла ягып шикаять язды. Аның белән булган урыс укытучылары да инспекторны яклап ялган шәһәдәт бирделәр. Имам Фазылҗан бу ялган яла ягуны әдәп белән инкяр итте. Авыл мулласын становой[7] һәм урядник[8] яклап: «Исерек инспектор ул авылдан кайтышлый безнең янга керде, һәм: «Мин (Фазылҗан) мулланы кыйнадым», — дип, безгә мактанды. Шуннан соң, бездән, зина кылырга хатын-кыз таләп итте», — диделәр. Становой белән урядник икесе дә урыс

7 Патша Россиясендә өлкә (губерния) полициясе башлыгы

8 Патша Россиясендә өлкә полициясенең түбән чины

булуга карамастан, прокуратура исерек инспекторның шикаяте файдасына хөкем итеп, мулла Фазылҗанны бер елга зинданга яптылар. Имам Фазылҗан хөкемне киредән тикшерүне таләп итеп сенатка хат язса да, сенат та прокуратураның хөкемен дөрес дип карар чыгарды.

### Чуваш авылларында булган вакыйга

Шушы ук елларда, Саратау (Саратов) өлкәсенә караган өч чуваш авылын Аллаһ һидәяткә күндереп, Исламны кабул иттеләр. Аларның кайберләре Ислам мәдрәсәләрендә укып гыйлем алдылар. Шуларның берсе мулла Ягъкуп.

Бу җирләргә Урыс хөкүмәте тарафыннан җаваплы булган, христианнарның атакае аларны Ислам диненнән мөшриклеккә яки христианлыкка кире кайтарырга бик нык тырышса да, ул авыллар барчасы да Исламда калуларын белдереп, попны инкяр иттеләр. Бигрәк тә мулла Ягъкуп һәм аның шәкертләре бу эштә авыл халкына бик тә зур тәэсир ясадылар.

Поп барча юлларны да кулланып тиешле нәтиҗә ала алмагач, тирә-яктагы урысларны җыеп, сәнәкләр һәм дә төрле таяклар вә кораллар белән коралланып мулла Ягъкуп авылына вәхшиләрчә һөҗүм ясыйлар. Барча авыл халкын Ислам динен кабул иткәннәре өчен генә бик каты кыйнап, мулла Ягъкупны үтерергә ниятлиләр. Урыс кәферләре мулланы вәхшиләрчә кыйнаганлыктан, имам хуштан язып җиргә мәет кебек сузылып ята. Урыслар: «Мулла Ягъкуп чыннан да үлдеме, әллә кыланып кына ятамы? Үлмәсә, үтерәбез», — дип, аның аяк тырнак араларына энәләр тыгып карыйлар. Имам хәрәкәт итеп бер терелек әсәре дә күрсәтмәгәч, үтердек дип уйлап кайтып китәләр.

Күпмедер вакыттан соң мулла Ягъкуп аңына килә, һәм авыл халкы барчасы да җыелып өяз башлыгына шикаять гаризасы язып җибәрәләр. Аларның авылы белән булган бу хәл беренче мәртәбә генә булмый инде.

Өяз башлыгы килеп тикшергәннән соң, һәм дә попның вә урысларның вәхши гамәлләрен белгәннән соң, попка

мөселманнар белән эш итүне тыялар. Поп нәтиҗәнең аның файдасына булмаганлыгын белеп: «Әгәр дә алар Исламда калса, киләчәктә барча мәҗүсиләр дә, мөшрикләр дә Исламга кереп бетәчәк», — дип ычкындыра.

1905нче елның 17нче октяберендә император тарафыннан диннәргә, сүзгә, каләмгә һәм намуска азатлык бирү карары игълан ителгәннән соң, бу авыллар иң беренче булып рәсми рәвештә Ислам кабул итүләрен белдерделәр.

### Мулла Мөхәммәдҗан әл-Кәүҗиякий вакыйгасы

«Уфа губернасы Минзәлә өязенә караган Нуркай белән Әлмәт авыллары арасында булган чуваш Бикмәт авылының ике гаиләсенә Аллаһ һидәят биреп, Исламны кабул итәләр.

Бу авылдан башка, якын-тирәләрдә башка чуваш авыллары булмый, хәтта бу авыл халкы да үз чуваш телләрен белми торган булалар. Кайберәүләр әйтүенчә, бу авыл халкы, вакытында Исламнан мәҗбүри рәвештә биздерелгән татарлар булалар. Тирә-якта гел татар авыллары булуы һәм бу авыл халкы да чуваш телләрен белмәве моңа дәлил булып тора. Шулай ук, авылның исеме дә Бикмөхәмməттән кыскартылып Бикмәт дип үзгәртелгән булса кирәк. Аллаһу әгъләм.

Исламны кабул иткән бу ике гаилә дә байлардан була. Ураза тоталар, намаз укыйлар, зәкәтләрен вә фитыр садакаларын бирәләр һәм дә якын-тирәдәге авыл муллаларыннан дини гыйлемнәр өйрәнәләр. Ләкин алар Исламны кабул итүләрен рәсми рәвештә игълан итмиләр, чөнки бу вакытларда аларга Ислам кабул итү рөхсәт ителмәгән була.

Бу ике гаиләнең Ислам кабул итүләре хөкүмәткә барып җиткәч тә, аларны вәгазьләргә дип атакайларны (попларны) җибәрәләр. Урыс хөкүмәтенең низамы буенча, бу чуваш авылы Карамалы авылы попының карамагында була. Поплар килеп Исламны кабул итүчеләрне ничек кенә вәгазьләсәләр дә, алар атакайларга буйсынмыйлар, ә бәлки Ислам кабул итүләрен ачыктан-ачык игълан кылалар. Шуннан соң аларны

кулга алу вә сөргенгә җибәрү белән куркыта башлыйлар. Алай да буйсындыра алмагач, Себергә сөрген кылалар.

Бу ике гаиләне сөрген кылу сәбәбендә, Аллаһ тәгалә авыл халкын тулысы белән диярлек һидәяткә күндерә, иллә-мәгәр ике гаилә генә авылда Исламны кабул итмичә мәҗүсилектә кала бирәләр. Авыл халкы күрше-тирә авыл муллаларыннан Ислам дине хөкемнәрен өйрәнеп, балаларын да Коръәнгә өйрәтә башлыйлар. Миссионерлар бу хәлне күреп, авылда чиркәү вә аның белән янәшә урыс-христиан мәктәбе төзетеп халыкны шунда йөртергә мәҗбүр кылырга уйлыйлар һәм бер попны билгелиләр. Чиркәүгә һәм мәктәпкә йөрмәгәннәрне сөргенлеккә сөрү белән яныйлар. Кемнәрдер попларны алдар өчен генә булса да чиркәүгә йөри башласа да, әмма ләкин күпчелек авыл халкын бу янаулар куркытмый.

Шул вакытларда, электән Себергә җибәрелгән теге ике гаилә кайтып төшә. Аларның иманнары тагы да ныграк куәтләнгән булып чыга, һәм алар авыл халкын вәгазьләп, үгет-нәсыйхәтләп диннәрендә нык торырга кушалар вә бу сөргеннәр һичнәрсә дә түгел икәнлеген аңлаталар.

Шуннан соң, поплар бу кешеләрне дин гыйлеменә укыткан күрше Кәүҗияк авылы мулласы һәм мөгаллиме Габдулгани бин Мөхәммәдҗанга бу эшен туктатырга кушалар. Мулла Габдулганинең әтисе мулла Мөхәммәдҗан попларга: «Безнең мәдрәсәбезгә гыйлем алырга киләләр икән, аның кем булуына карамастан, без аңа динне өйрәтергә тиешлебез. Әгәр дә син аларның бу эшен тыясың килә икән, каравылчы вә сакчы куй аларга», — дип, попны инкяр итә.

Поплар, Кәүҗияк муллалары Мөхәммәдҗан белән Габдулгани өстеннән хөкүмәткә шикаять язалар. Күп вакыт үтми аларның икесен дә сорау алырга чакырталар. Мулла Мөхәммәдҗан сорау алучыга попларга әйткән сүзләрне үк әйтә, һәм өстәп: «Ислам, безнең динебезне өйрәнергә теләүче кешенең кем булуына карамастан, аңа гыйлем бирергә куша. Булсын ул мәҗүси яки урыс, хәтта син, синең балаң яки синнән югары вазыйфалы бер түрә булса да Ислам хөкемнәрен өйрәнергә телисез икән,

без аңа өйрәтәчәкбез. Әгәр дә без, гыйлем алырга теләгән кешене инкяр итсәк, гөнаһлы булабыз», —диде, һәм ошбу Коръән аятьләрен укыды, мәгънәсе: **«Аллаһ китап әһелләреннән, китаптагы Аллаһ хөкемнәрен кешеләргә ирештерергә һәм бер хөкемне дә яшермәскә, дип гаһед (вәгъдә) алды. Алар вәгъдәләрен һәм кешеләргә китаптагы Аллаһ хөкемнәрен ирештерү бурычларын артларына ыргытып, аны аз акчага саттылар. Аллаһ хөкемнәрен дөнья малына алыштырулары — нинди кабахәт гамәлдер».** [Әл-Гыймран 187] Мулла Мөхәммәдҗан дәвам итеп: «Аллаһ тәгалә бу аятьләрдә, безгә китап әһелләре кебек булмаска кушты», — диде. Сорау алучы жандарм аңа: «Сезнең бу гамәлегез дәүләткә каршы килә, ә сез дәүләткә буйсыну вәгъдәсен бозмаска тиешсез», — диде. Мулла Мөхәмәдҗан аңа: «Аллаһ тәгалә Бөек һәм Аның хакы да сезнең хакыгызга караганда күпкә өстенрәк вә әүвәлрәк. Без сезгә барча нәрсәдә дә буйсынабыз дип вәгъдә итмәдек, иллә-мәгәр Аллаһның шәригатенә каршы килмәгән нәрсәләрдә генә буйсынырга вәгъдә иттек. Ә инде гөнаһлы эшләрдә һәм Аллаһның хөкеменә каршы килгән нәрсәләрдә, без беркемгә дә буйсына алмыйбыз. Шулай булгач, сез, Урыс хөкүмәте, безнең шәригатебезгә каршы килгән нәрсәләргә безне чакырмагыз вә әмер итмәгез!», — дип, кискен генә, батырларча җавап бирде.

Урыс жандармнары мулла Мөхәммәднең һәм улы мулла Габдулганинең ныклы карашларын какшата алмаячакларын белгәч, аларның икесен дә Уфа төрмәсенә яптылар.

Мулла Мөхәммәдҗан 1892нче елларда Уфа төрмәсендә вафат булды, Аллаһның рәхмәте булсын аңа. Ә инде улы, мулла Габдулганине Себергә сөрген кылдылар. Ул Иркутск шәһәренә 70 чакрым ераклыктагы, Байкал күле янында бер авылда имам булып тора, һәм аңа якынча 70 яшь», — дип яза Рамзий 20нче гасыр башында.

Бу татар халкының, диннәрен вә милләтләрен саклап калуда булган көрәшләреннән, кайбер кечкенә сурәтләр генә. Безнең үз динебезне, тарихыбызны белмәвебез, хәзерге заманаларда нинди кызганыч вә аяныч хәлләргә китерде. Эч-

кечелек, наркомания, кеше үтерү, зина, урлашу, тәрбиясезлек һәм башкалар, болар барсы да зур мөселман милләтен юкка чыгару өчен эшләнгән эшләрнең нәтиҗәсе булып тора.

Әй татарлар, уяныгыз,
Исте Кыйбла җилләре.
Дөнья белән яшәү бетми,
Тормыш алда бит әле.
Динебезгә кара ягып,
Безне бик күп кактылар.
Байлык белән акча өчен,
Намусларын саттылар.
Кайтыгыз сез бабаларның,
Мирас иткән диненә.
Аллаһ биргән туры юлга,
Пәйгамбәрләр сүзенә.
Әгәр дә, без Аллаһ кушкан
Гамәлләрне үтәсәк.
Пәйгамбәребез калдырган
Сөннәтенә тотынсак,
Шул вакытта дөньябызга
Мәрхәмәтлек киләчәк!